Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советының илле сигезенче утырышы

Надеждино авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

29 май, 2020 ел № 148

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 маендагы 8 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» гы карарына үзгәрешләр һәм тәгалләштерүләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге советы карар чыгарды:**

1. «Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» 2015 елның 12 маендагы 8 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм тәгалләштерүләрне кертергә:

1.1. Карар һәм кушымта исемендә, шулай ук 1 пункт текстында «өченче чакырылыш» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Бермандатлы сайлау округлары тасвирламасын (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге Советы карарына кушымта 2015 елның 12 маендагы 8 номерлы Надеждино бермандатлы 2 номерлы сайлау округына Мәктәп урамын кертеп тәгалләштерергә:

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З. Галяветдинов